КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 17 апрель г.Казань № 441

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 741 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1049 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1165 нче; 2021 ел, 11 май, 325 нче; 2021 ел, 31 май, 416 нчы; 2021 ел, 12 июнь, 446 нчы; 2022 ел, 3 июнь, 514 нче; 2022 ел, 11 июнь, 550 нче; 2022 ел, 20 декабрь, 1374 нче; 2023 ел, 25 май, 639 нчы; 2023 ел, 15 декабрь, 1615 нче; 2024 ел, 22 апрель, 269 нчы; 2024 ел, 20 май, 344 нче; 2025 ел, 19 май, 334 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның дүртенче абзацында «берәмлекләре» сүзен «районнары» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл территорияләре дигәндә әлеге Кагыйдәләрдә авыл торак пунктлары, шәһәр тибындагы поселоклар һәм авылара территорияләр (территорияләрендә административ үзәкләр урнашкан шәһәр округлары составына керә торган авыл торак пунктларыннан һәм шәһәр тибындагы поселоклардан тыш) аңлашыла.

Татарстан Республикасының авыл территорияләре исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

әлеге карар белән расланган Торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

1 пунктта:

сигезенче абзацта «терәк торак пунктында урнашкан» сүзләрен «авыл агломерациясендә урнашкан» сүзләренә алмаштырырга, «(инвестиция фондыннан, шул исәптән аның идарәче компаниясеннән тыш)» сүзләрен «(инвестиция фондының идарәче компаниясеннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак урынны наемга алу шартнамәсе буенча торак алучы гражданның эш бирүчесе булып урта һөнәри белем бирү, югары белем бирү мәгариф программаларын, һөнәри белем бирүнең төп программаларын, өстәмә һөнәри программаларны гамәлгә ашыручы һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы, яисә Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәте, яисә Балыкчылык федераль агентлыгы (алга таба – профильле белем бирү оешмасы) карамагындагы мәгариф оешмасы, яисә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы, яисә Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәте, яисә Балыкчылык федераль агентлыгы карамагындагы фәнни оешма (алга таба – профильле фәнни учреждение) торса, авыл территорияләрендә һәм авыл агломерацияләрендә урнашкан күпфатирлы йорттагы торак урынны мондый торак урынның беренче һәм бердәнбер милекчесе булган һәм күчемсез мөлкәт объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алганнан соң әлеге торак урынга милек хокукын теркәгән юридик заттан (инвестиция фондының идарәче компаниясеннән тыш) яисә индивидуаль эшмәкәрдән сатып алу.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Федераль бюджет акчасы исәбеннән төзелгән индивидуаль торак төзелеше объектын, блоклы төзелеш йортын, торак урынны субсидия акчасы исәбеннән сатып алу рөхсәт ителми.»;

2 пунктның икенче, өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл территорияләре – авыл торак пунктлары, шәһәр тибындагы поселоклар һәм авылара территорияләр (территорияләрендә административ үзәкләр урнашкан шәһәр округлары составына керә торган авыл торак пунктларыннан һәм шәһәр тибындагы поселоклардан тыш). Татарстан Республикасының авыл территорияләре исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана;

авыл агломерациясе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган терәк торак пункт һәм аның тирәсендәге территорияләр җыелмасы;

әлеге Тәртиптә кулланыла торган «терәк торак пункт» һәм «янәшәдәге территория» төшенчәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 28 декабрендәге

4146-р номерлы боерыгы белән расланган 2036 елга кадәр фараз белән 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең пространство үсеше стратегиясендә каралган төшенчәләргә туры килә;»;

әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

исемендә «берәмлекләре» сүзен «районнары» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Кагыйдәләр авыл территорияләрендә һәм авыл агломерацияләрендә җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү буенча иҗтимагый әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган вәкаләтләрне башкарганда җирле үзидарә органнарына дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына субсидияләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – проектлар, субсидияләр) бирү һәм бүлү тәртибен һәм шартларын билгели:

а) «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына теркәлгән 15 нче кушымта нигезендә субсидияләр бирү өчен сайлап алынган, Татарстан Республикасы буенча авыл агломерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеш планына кертелгән терәк торак пункт территориясендә гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган проект;

б) Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган проект.

Бу Кагыйдәләр максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

авыл территорияләре – авыл торак пунктлары, шәһәр тибындагы поселоклар һәм авылара территорияләр (территорияләрендә административ үзәкләр урнашкан шәһәр округлары составына керә торган авыл торак пунктларыннан һәм шәһәр тибындагы поселоклардан тыш). Татарстан Республикасының авыл территорияләре исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана;

авыл агломерациясе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган терәк торак пункт һәм аның тирәсендәге территорияләр җыелмасы;

әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган «терәк торак пункт» һәм «янәшәдәге территория» төшенчәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 28 декабрендәге 4146-р номерлы боерыгы белән расланган 2036 елга кадәр фараз белән 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең пространство үсеше стратегиясендә каралган төшенчәләргә туры килә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр түбәндәге юнәлешләр буенча проектларны гамәлгә ашыруга бирелә:

а) парклар, мәйданнар, скверлар, яр буйлары территорияләрендә һәм бер яисә берничә функциональ зоналы яшелләндерелгән территорияләрдә комплекслы ачык җәмәгать пространстволары булдыру һәм төзекләндерү;

б) ишегалды территорияләрен төзекләндерү;

в) урам-юл челтәрен төзекләндерү;

в) балалар өчен уен мәйданчыкларын булдыру һәм төзекләндерү;

г) сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спорт мәйданчыклары, адаптив физик культура һәм адаптив спорт белән шөгыльләнү мәйданчыклары булдыру һәм төзекләндерү;

д) мәдәни әһәмияткә ия объектларны булдыру, саклау һәм торгызу;

е) территорияне механикалаштырылган җыештыру һәм карап тоту өчен техника сатып алу.

Проектларга кертелә торган чараларның минималь исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына теркәлгән 7 нче кушымтада китерелгән Авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең кушымтасында билгеләнде.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бүлү Министрлык тарафыннан сайлап алынган һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына чираттагы финанс елына һәм план чорына субсидия бирү турындагы заявка составында җибәрелгән проектлар исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән проектларны гамәлгә ашыру өчен беренчел чиратта;

б) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән проектларны әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән проектларның смета кыйммәтенә пропорциональ рәвештә әлеге проектларның гомуми смета кыйммәтендә гамәлгә ашыру өчен.

Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләр бүленеше агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Тиешле финанс елына муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

а) әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы ($C_{ia}$) нигезендә түбәндәге формула буенча:

$$C_{ia} = SUM (Z_1 + Z_2 +... + Z_n),$$

монда:

$Z_1$, $Z_2$, ..., $Z_n$ – проектларны гамәлгә ашыруга субсидия бирү өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан бирелгән заявка буенча әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән юнәлеш нигезендә һәр проект буенча

субсидия күләме.

Һәр проектны гамәлгә ашыруга субсидия күләме 15 млн.сумнан артмаска тиеш һәм проектның гомуми финанслау күләменең иң күбе 50 процентын тәшкил итә. Шул ук вакытта проектны финанслау күләменең кимендә 50 проценты бюджеттан тыш акча исәбеннән (материаллар бирү һәм (яисә) җиһазлар сатып алу рәвешендә индивидуаль эшмәкәрләрнең һәм (яисә) юридик затларның акчасы яисә кертемнәре рәвешендә) тәэмин ителергә тиеш;

б) әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы ($C_{ib}$) нигезендә түбәндәге формула буенча:

$$C_{ib} = SUM\ (Z_1 + Z_2 + ... + Z_n),$$

монда:

$Z_1$, $Z_2$, ..., $Z_n$ – проектларны гамәлгә ашыруга субсидия бирү өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан бирелгән заявка буенча әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр нигезендә һәр проект буенча субсидия күләме.

Һәр проектны гамәлгә ашыруга субсидия күләме 3 млн.сумнан артмаска тиеш һәм проектның гомуми финанслау күләменең иң күбе 70 процентын тәшкил итә. Шул ук вакытта проектны финанслау күләменең кимендә 15 проценты бюджеттан тыш акча исәбеннән (материаллар бирү һәм (яисә) җиһазлар сатып алу рәвешендә индивидуаль эшмәкәрләрнең һәм (яисә) юридик затларның акчасы яисә кертемнәре рәвешендә) тәэмин ителергә тиеш.»;

әлеге карар белән расланган Торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен формалаштыру, раслау һәм аларга үзгәреш кертү тәртибендә:

24 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Әлеге Тәртип нигезендә төзелгән (сатып алынган) торак урыннар (торак йортлар) коммерциячел файдаланудагы торак фондына карый һәм гражданнарга Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә торак урынны наемга алу шартнамәсе буенча түләүле биләүгә һәм файдалануга бирелә. Әлеге шартнамәдә гражданның эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе буенча кимендә 10 ел эшләү срогы карала, шул вакыттан соң граждан әлеге торак урынны үз милкенә торак төзү (сатып алу) өчен хисап кыйммәтенең 1 процентыннан артмаган бәядән (алга таба – торакны сатып алу бәясе) сатып алырга хокуклы. Торакны сатып алу бәясе күләмендә акча түләү торак урынны яллаучыларның теләге буенча әлеге срок дәвамында ай саен (квартал саен) тигез өлешләрдә  вакытыннан алда түләүләр кертү хокукыннан тыш башкарылырга мөмкин.»;

25 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) торак урынны яллаучының торак урын наемы шартнамәсе рәсмиләштерелгән көннән алып, торак урын бирелә торган муниципаль район (шәһәр җирлеге, муниципаль округ, шәһәр округы) чикләрендәге авыл территорияләрендә, терәк торак пунктлар территорияләрендә, янәшәдәге территорияләрдә эш бирүчедә хезмәт шартнамәсе буенча торак урын яллаучы кимендә 10 ел дәвамында эшләве

(әлеге пунктның «б» пунктчасында күрсәтелгән очрактан тыш), әгәр гражданның әлеге Нигезләмәдәге 4 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән шартка туры килгәндә торак алу хокукы барлыкка килгән очракта – торак урынны яллаучының торак урын наемы шартнамәсе рәсми-ләштерелгән көннән алып кимендә 10 ел эчендә профильле мәгариф оешмасында яисә профильле фәнни учреждениедә хезмәт шартнамәсе буенча эшләве;»;

түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәргә:

«в) Нигезләмәнең 4 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән гражданны Нигезләмәнең 1 пунктындагы тугызынчы абзацында күрсәтелгән торак урында яшәү урыны (булу урыны) буенча теркәү.»;

27 пунктның беренче җөмләсенә «хәрби хезмәткәрнең әлеге Тәртипнең 25 пунктында каралган торак урынны наемга алу шартнамәсе шартларын үтәвенә карамастан, әмма хәрби хезмәткәрнең эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе төзелгәннән соң биш елдан да иртәрәк булмаган вакыт эчендә» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Эл.Хөк., А.М.Сәгыйтова